ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
КАРАР

№ 5 12 ноябрь 2025 ел

«Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге
Татар Сөнчәлесе авылында гражданнарның үзара салым кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомум принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законны 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 2 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарста Республикасы Аксубай муниципаль районы «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлег Уста́вының 22 статьясы нигезендә КАРАР бирәм:

1. 2025 ел 21 ноябрь 14 сәгать 00 минутка ТР, Аксубай муниципаль районы, Татар Сөнчәл авылы, Тукай урамы, 12 йорт адресы буенча Татар Сөнчәле авыл клубы бинасынд Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Татар Сөнчәл авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә..
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Татар Сөнчәл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төрке инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алуч студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрб хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 1000 сум күләменд үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирл әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карата юл эшчәнлеге;**

• Татар Сөнчәле торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә и булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (вак таш сатып алу, торак пункт юллар чокырларын ремонтлау, кышкы чорда юлларны кардан чистарту-эшләр өчен шартнам буенча түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

• **Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндер өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, җирлек территориясен төзекләндер кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралар объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидлар файдалана алуы тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясе төзекләндерүне оештыру:**

• Татар Сөнчәле торак пунктының башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакыт территорияләрне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, триммер сать алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү)

• Татар Сөнчәле торак пунктында урамнарны яктырту җайланмасы (товарла материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрнең күпләп җыела торган урыннары стендларга һәм такталарга беркетү, элү юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук Аксуба муниципаль районы «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайты урнаштырырга.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

СОВЕТ МЮДОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы Т.В. Зюзина